ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 24 декабрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2019 елның 9 декабре) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе (алга таба – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы)» сүзләренә алмаштырырга;

2) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында
җирле үзидарә турында» Татарстан
Республикасы Законына
кушымта

**Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлеге**

1) Азнакай муниципаль районы;
2) Әлки муниципаль районы;
3) Әлмәт муниципаль районы;
4) Апас муниципаль районы;
5) Арча муниципаль районы;
6) Балтач муниципаль районы;
7) Бөгелмә муниципаль районы;
8) Буа муниципаль районы;
9) Югары Ослан муниципаль районы;
10) Биектау муниципаль районы;
11) Алабуга муниципаль районы;
12) Зәй муниципаль районы;
13) Зеленодольск муниципаль районы;
14) Кама Тамагы муниципаль районы;
15) Кукмара муниципаль районы;
16) Лаеш муниципаль районы;
17) Лениногорск муниципаль районы;
18) Менделеевск муниципаль районы;
19) Минзәлә муниципаль районы;
20) Түбән Кама муниципаль районы;
21) Нурлат муниципаль районы;
22) Яңа Чишмә муниципаль районы;
23) Питрәч муниципаль районы;
24) Балык Бистәсе муниципаль районы;
25) Саба муниципаль районы;
26) Тукай муниципаль районы;
27) Теләче муниципаль районы;
28) Чистай муниципаль районы;
29) Чаллы шәһәре.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 4; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе (алга таба – Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы)» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлеге турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Закон исемендә «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 статьяда «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 4 статьяның 4 өлешендә «проектларына экспертиза» сүзләрен «проектларын карау» сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

«2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның 3.2.3 пунктындагы 3.2.3.8 пунктчасының «Пространстволы үсешне координацияләү» бүлегендәге икенче абзацында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 28 (I өлеш), «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**5 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 25 декабрь
№ 112-ТРЗ